**Каралган**
МБ житәкчесе
______/Нәҗметдинова Л.Ә./
Беркетмә № 1
«25»август 2014 ел.

**Килешенгән**
«Яңа Мәлкән гомуми төп белем мәктәбе» ГБМУ нең УТЭБДУ
______/Сәгъдиева Г.Ф./
«25»август 2014 ел.

**Раслыйм**
«Яңа Мәлкән гомуми төп белем мәктәбе» ГБМУ нең директоры
______/ Әхмәтшина Э.Л./
Приказ №_ 94
«27»август 2014 ел.

Уку фәненнән

ЭШ ПРОГРАММАСЫ

Татарстан Республикасы, Минзәлә муниципаль районы

“Яңа Мәлкән ТГБМ” ГББМУ

Нәҗметдинова Ләлә Әсхәт кызы, икенче квалификацион категорияле укытучы

татар әдәбияты, 5 нче сыйныф

Педагогик совет
утырышында каралган
беркетмә № 1
« 25 »август 2014 ел.

2014 – 2015 нче уку елы

**Аңлатма язуы.**

**5 нче сыйныфта** татар әдәбиятыннан эш программасы түбәндәге документларны исәпкә алып төзелә:

1. 2012 нче елның 29 нчы декабреннән гамәлгә кергән“РФ дә Мәгариф турында”273 нче федераль кануны (“Закон об образовании в РФ” )
2. Татарстан Республикасының “Мәгариф турындагы кануны.
3. “Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында” Татарстан Республикасы Законы.
4. Татар телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләре өчен ана теле һәм әдәбиятыннан ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының 933/14 нче №лы боерыгы белән расланган урнәк программа
5. “Татар телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләре өчен татар әдәбиятыннан программа” (5-9 нчы сыйныфлар) Төзүче авторлар: Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова, Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2013 ел.
6. Ф.Ә.Ганиева, Л.Г.Сабировалар төзегән “Татар телендә гомуми төп белем бирү мәктәпләренең 5 нче сыйныфы өчен татар әдәбиятыннан авторлык (эш) программасы (Казан, 2014 нче ел)
7. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының “Федераль дәүләт белем стандартлары нигезендә мәктәпләрдә татар телен һәм әдәбиятын укыту турында”гы 17291/14 № лы хаты (04.09.2014.)
8. ТРның гомумбелем мәктәпләре өчен чыгарылган базис уку-укыту планы (2012 нче ел)
9. “Яңа Мәлкән ГБМУ” ның 2014/15 нче уку елына уку-укыту планнары (25.08.2014 нче ел датасы белән чыгарылган 91 нче № лы боерык);
10. “Яңа Мәлкән ГБМУ” ның уку фәннәреннән эш программасын төзү турындагы положениесе (Положение о рабочей программе учебного предмета, курса, дисциплины (модуля) МБОУ «Новомелькенская ООШ» Мензелинского муниципального района РТ)

**Татар әдәбиятыннан гомуми белем бирүнең максатлары:**

- Әдәби әсәрләрне бала күңеленә сеңдерү, аларның мәгънәсен, нәфислеген төшендерү.
- Укучыларда күркәм сыйфатлар тәрбияләргә булышу.
- Әсәрләрне күбрәк укырга теләк уяту һәм тәрбияләү.

**Бурычлар:**

1. Өйрәнелгән әдәби әсәрләрне чорларның үсеш тәртибендә системалы итеп күзалларга ярдәм итү.
2. Әдәби әсәрнең төрен һәм жанрын билгеләргә өйрәтү.
3. Әдәби әсәрне өлешчә анализлау күнекмәләре булдыру.
4. Шигъри текстларны яисә чәчмә әсәрләрдән өзекләрне ятлату.
5. Укучының мөстәкыйль фикерләвен, гомумиләштереп нәтиҗәләр ясау сәләтен үстерү.

**5 нче сыйныфта татар әдәбиятыннан белем бирүнең максатлары**

- Татар әдәбиятының бай тарихын, классик язучыларының иҗатларын һәм иң күренекле әсәрләрне өйрәнү, үзләштерү
- Иң күркәм әсәрләр мисалында рухи байлыкның кыйммәтен күрсәтү, дәрәҗәсен күтәрү
- Укучыда кызыксыну хисен уяту, белем алуга, иҗади һәм рухи үсүгә теләк – омтылыш тудыру, укучының иҗади сәләтен үстерү.

**Бурычлар**

1. Өйрәнелгән әдәби әсәрләрне чорларның үсеш тәртибендә системалы итеп күзалларга ярдәм итү.
2. Әдәби әсәрнең төрен һәм жанрын билгеләргә өйрәтү.
3. Әдәби әсәрне өлешчә анализлау күнекмәләре булдыру.
4. Шигъри текстларны яисә чәчмә әсәрләрдән өзекләрне ятлату.
5. Укучының мөстәкыйль фикерләвен, гомумиләштереп нәтиҗәләр ясау сәләтен үстерү.

**Уку предметына гомуми характеристика**

Сүз сәнгате булган әдәбият – тормышны үзенчәлекле танып белү формасы, ул хисси-эмоциональ тәэсир чаралары ярдәмендә дөнья сурәтен, моделен төзү һәм шуңа карата мөнәсәбәт формалаштыру сәләтенә ия. Мәктәптә укыту предметы буларак ул әхлакый-эстетик һәм интеллектуаль әзерлекле шәхес, гражданин тәрбияләүдә турыдан туры катнаша. Укучы әдәби әсәрләр, аларның авторлары фикере аша гомумкешелек кыйммәтләрен, халыкның рухи байлыгын үзләштерә - тормыш фәлсәфәсенә төшенә. Шуңа күрә гомуми белем бирү системасында бу укыту предметының әһәмияте зур.

**Әдәбият фәненең тоткан урыны.**

2013 нче елда ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән программа буенча (төзүче –авторлары Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова) 5 нче сыйныф өчен программада әдәбиятка 70 дәрес каралган, ТР Минзәлә муниципаль районы МБГББУ “Яңа Мәлкән төп гомуми белем бирү мәктәбе” 2014- 2015 нче уку елына укыту планы буенча 5 нче сыйныфта уку елы дәвамында 70 дәрес (атнага 2 сәгать) үткәрү планлаштырыла.

**Курсның эчтәлеге**

| № | Бүлек | Сәгать саны | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Автор программасында | Эш программасында | Корректировка |
| 1 | Әдәбиятны өйрәнү | 58 | 58 | - |
| 2 | Бәйләнешле сөйләм үстерү | 8 | 8 | - |
| 3 | Дәрестән тыш уку | 4 | 5 | - |
| | Барлыгы | 70 | 70 | |

Программа эчтәлеге:

Халыкның милли, рухи мәдәният хәзинәсе буларак **халык иҗаты.**

Аның сәнгать төрләре формалашуга йогынтысы. Халык иҗатының бер төре буларак **халык авыз иҗаты.** Аның әсәрләрендә гомумкешелек хыяллары, идеалларының чагылуы. Халык авыз иҗатының матур әдәбият белән бәйлә-нешләре: уртаклыгы һәм үзенчәлекле аермалары. Халык авыз иҗатының төп жанрлары, жанр сыйфатлары. **(1 сәг.)**

**Әкиятләр:** жанр төрләре, үзенчәлекле сыйфатлары.

"Ак бүре" әкияте (кыскартып). **(4 сәг.)**

"Үги кыз", "Аю белән төлке" әкиятләре. **(4 сәг.)**

**Җырлар:** татар халык җырларына хас үзенчәлекләр. Көй һәм сүзләр тәңгәллеге. "Моң" төшенчәсе. Җырларны төркемләү. "Иске кара урман", "Гөлҗамал","Туган ил","Яшә, Республикам!","Ай былбылым"; кыска җырлар - дүртюллыклар; тарихи җырлар: "Болгар иленең кызлары","Пугач явы". **(4 сәг.)**

**Кыска жанрлар: мәкальләр һәм әйтемнәр. табышмаклар, мәзәкләр**. "Хуҗа Насретдин мәзәкләре**".** **(4 сәг.)**

**Бәетләр.** "Сак-сок" бәете. **(2 сәг.)**

**Риваятьләр, легендалар:** аларга хас үзенчәлекләр**;** жанр сыйфатлары.

"Янмый торган кыз","Иске Казан каласының корылуы","Шәһәр нигә Казан дип аталган","Әллүки","Зөһрә кыз","Кеше гомере ничек корылган**".( 6 сәг.)**

**Практик дәрес:** халык авыз иҗатында образлар**;** әсәрләрдә дөньясурәте; табигать һәм кеше, яшәеш һәм кеше турында күзаллаулар. Халык авыз иҗаты поэтикасы, язма әдәбият үсешенә, әдәби телгә зур йогынтысы. **(2 сәг.)**

**Әдәби әкиятләр**: халык әкиятләре белән уртаклык; сәнгатьлелек сыйфатлары, әдәби әсәр буларак алым һәм сурәтләү чаралары.

**Г.Тукайның** "Шүрәле" әкияте**.** **(2 сәг.)**

**Ж.Тәрҗемановның** "Тукран малае Шуктуган" әкияте. **(4 сәг.)**

**Әхмәт Фәйзинең** "Аучы мәргән белән Болан кыз" әкияте. **(3 сәг.)**

**Рабит Батулланың** "Курай уйный бер малай" әкияте**.** **(3 сәг.)**

**Фәнис Яруллинның** "Зәңгәр күлдә ай коена","Кояштагы тап"әкиятләре **(3 сәг)**

**Хикәя:** жанр сыйфатлары; әсәрнең катламнары – вакыйгалар, күренешләр, хис-кичерешләр; кеше образлары - төп герой, ярдәмче геройлар, җыелма образлар; хикәяләүче образы, автор позициясе.

**Фатих Әмирханның** “Ай өстендә Зөһрә кыз”,”Нәҗип” хикәяләре. (**5 сәг.)**

**Мәсәл.** Тереклек, җансыз предмет образлары ярдәмендә, читләтеп, кеше сыйфатларын һәм тормышын тасвирлау. Хикәяләп яки тезмә рәвештә язылуы; фикер-идеяләрнең аллегория ярдәмендә белдерелүе.

**Мәҗит Гафуриның** “Сарыкны кем ашаган?” мәсәле. **(1 сәг.)**

**Габдулла Тукайның** “Ике сабан” мәсәле. **(1 сәг.)**

**Практик дәрес:** сәнгатьтөре буларак матур әдәбят; чәчмә һәм тезмә әсәр;

аларның сәнгатьчә сурәтләү алымнары, чаралары. **(2 сәг.)**

**Габдулла Тукайның** “Пар ат”,”Туган җиремә”,”Туган авыл” шигырьләре. **(3 сәг.)**

**Шәүкәт Галиев.** Балалар әдәбиятындагы урыны; геройлары, образлар дөньясы. “Һәркем әйтә дөресен”,”Тереклек суы”,”Курыкма, тимим!”

“Тарихтан сабак”,”Өйгә бирелгән эш”,”Онытылган, өйдә калган” шигырьләре. **(4 сәг.)**

**Бәйләнешле сөйләм үстерү - 8 сәгать:**

**Ятлау һәм сәнгатьле итеп сөйләү өчен әсәрләр:**

1. Г.Тукайның “Шүрәле” әсәре, 1 – бүлек.
2. Г.Тукайның үзегез яраткан шигыре.
3. Ф.Яруллинның “Сез иң гүзәл кеше икәнсез” шигыре.
4. Укытучы яки укучылар сайлап алып, Ш.Галиевнең бер шигыре.

**Инша язу өчен үрнәк темалар**:

1. Әкият геройларының көрәш максатлары һәм җиңүгә китергән сәбәпләр, шартлар (өйрәнгән әсәрләр мисалында).
2.“Сак-сок”бәетендә тасвирланган халык акылы һәм синең үз нәтиҗәләрең.
3. Әдәби әкиятләрдә табигать һәм кеше образларына салынган фикерләр, нәтиҗәләр (өйрәнгән әсәрләр мисалында).
4.”Минем туган җирем” (Г.Тукай һәм башка язучыларның әсәрләрен файда- ланып, һәркем үз образын иҗат итә).

**Дәрестән тыш уку өчен - 4 сәгать:**

1. “Гөлчәчәк” татар халык әкияте.
2. Ләбиб Лерон. Шаян хикәяләр, шигырьләр, әкиятләр.
3.Фаил Шәфигуллинның “Акмөгез”хикәясе.
4. Вакытлы матбугат басмалары.

**Күнекмәләр формалаштыру:**

**рецептив (өлешләп, бүлекләп үзләштерү) эшчәнлек:**

- халык авыз иҗатын,аның аның жанрларын, үзенчәлекләрен тану;
- әдәби текстны сәнгатьле уку, аны аңлата алу, яттан сөйли белү;
- язучының тормыш юлын, аның төп әсәрләрен истә калдырып сөйли алу;
- әдәби әсәрнең төрен, жанрын билгеләү, фикерне исбатлый белү;

**репродуктив (хәтергә күчереп алып үзләштерү) эшчәнлек:**

- әдәби әсәрнең сюжетын, анда тасвирланган вакыйгаларны, характерларны аңлатып бирә, бәяли алу;
- төрле мәгълүмат чыганаклары: сүзлекләр, белешмәләр, энциклопедияләр, электрон чаралар белән максатчан эшли белү;

**иҗади эшчәнлек**:

- халык авыз иҗаты әсәрләрен аңлап, сәнгатьле итеп укый белү;
- укыганны, күз алдына китереп, җанлы итеп сөйли белү; рольләргә кереп кабатлап бирә алу;
- шигырьләрнең образларын танып, басым һәм паузаларны, интонацияне дөрес билгеләп, укый белү;
- хикәяләп язылган язылган әдәби әсәрне фикер сөрешен аңлап уку, хәтерләп бару; укыганны үз сөйләмеңдә сурәтләп бирә алу;
- вакыйгалар барышын, әсәрдәге әһәмиятле өлеш, борылышларны күздә тотып, план төзи белү;

**эзләнү эшчәнлеге:**

- куелган сорауларга, мөстәкыйль уйланып, җавап бирә алу;
- төрле чыганаклардан файдалана алу - сорауның кайсы өлкәдән, нинди темага бәйле икәнлеген белеп эзләү.

## <u>Программаны үзләштерүдә көтелгән нәтиҗәләр.</u>

**Формалаштырылган белем-күнекмәләр (уку елы башына)**

Укучы:

- укылган текстның эчтәлеген аңлый һәм аның темасын билгели ала;
- әсәрнең мәгънәле кисәкләре арасындагы бәйләнешләрне ачыклап, төп фикерне билгели, аны үз сүзләре белән әйтеп бирә;
- укылганга тулы, кыска һәм рәсемле план төзи;

- укылганның эчтәлеген тулысынча, кыскача, сайлап һәм иҗади сөйли ала; сөйләгәндә тасвирлама, фикер йөртү элементларын файдалана, цитаталар китерә;
- хикәянең башламын, мөмкин булган дәвамын һәм ахырын уйлап чыгара ала;
- текстта автор һәи катнашучыларның сүзләрен, табигать һәм көнкүреш тасвирламаларын аерып күрсәтә;
- мөстәкыйль рәвештә яки укытучы ярдәмендә әсәрнең төп геройларына бик гади характеристика бирә ала;
- укытучы һәм сыйныфташлар укыган әсәрнең, сабакташ җавабының эчтәлеген аңлап һәм тулы үзләштерә;
- һәртөрле башкарылган эшнең, биремнең үтәлешен бәяли ала;
- яттан 15 тән дә ким булмаган шигырь белә;
- 2-3 зур күләмле әсәрнең (фольклор һәм мәшһүр язучыларның әсәрләре) исемен, темасын әйтә, сюжетларын бәян итә ала;
- 6-7 халык әкиятенең эчтәлеген, 10 нан артык мәкаль һәм әйтем, 2-3 тапкыр тәгъбир (аларның мәгънәсен аңлап, ситуациядә урынлы кулланып) белә;
- бер минутка 85-95 сүздән торган текстны дөрес итеп укый, эчтәлеген аңлый һәм сөйли ала.

**Формалаштырылырга тиешле белем-күнекмәләр (уку елы ахырына)**

1. Сүз сәнгатенең образлы табигате турында күзаллау булу.
2. Классик әдипләребезнең тормыш һәм иҗат юлларыннан төп фактларны белү.
3. Өйрәнелгән төп әдәби-теоретик төшенчәләрне белү.
4. Әдәби текстның сюжетын сөйли белү.
5. Өйрәнелә торган әсәрнең аерым эпизодын (яисә күренешне) анализлый алу.
6. Әдәби әсәрнең төрен һәм жанрын ачыклый белү.
7. Әдәби әсәрләрне чагыштыра белү.
8. Әдәби әйтелеш таләпләрен саклаган хәлдә өйрәнелгән әсәрләрне (өзекне) сәнгатьле итеп уку.
9. Өйрәнелгән әсәргә дәлилле рәвештә үз мөнәсәбәтеңне белдерү.
10. Рус һәм татар телендәге уртак һәм милли үзенчәлекләрен билгеләү, әхлакый кыйммәтләрнең чагылышын чагыштырып бәяләү.
11. Татар һәм рус телендәге әсәрләргә телдән һәм язмача фикереңне белдерү, аларга бәя бирү.
12. Диалогта яисә бәхәстә катнашу.
13. Сүз сәнгатенең аерым күренешләре белән мөстәкыйль танышу һәм аларның эстетик кыйммәтен бәяләү (класстан тыш вакытта әсәр укуга ихтыяҗ булу).
14. Татар әдәби теленең нормаларына нигезләнеп, кирәкле темага телдән һәм язмача бәйләнешле текст төзү күнекмәсенә ия булу.

**Бәяләү системасы**

Укучыларның уку барышында алган белем-күнекмәләрен бәяләп бару укыту процессының мөһим өлешен тәшкил итә, аның әһәмияте, максаты укучыларның белемнәрен даими күзәтеп, бәяләп бару белән билгеләнә.

Уку күнекмәләрен тикшерү өчен биремнәр: әдәби текстны аңлап, дөрес, йөгерек һәм сәнгатьле уку, әдәби әйтелеш нормаларын саклап, дөрес интонация һәм басым белән уку, текстның төп мәгънәсен, эчтәлеген аңлап, эчтән уку һәм кирәкле информацияне табу һ.б.

Сөйләм күнекмәләрен бәяләү өчен биремнәр: әсәрнең эчтәлеген бәян итү яки тәкъдим ителгән аерым өзекләрен яттан сөйләү, әсәрнең геройлары, вакыйгалары турында текст төзеп, хикәяләп сөйләү, бирелгән темага хикәя төзеп сөйләү, язучының биографиясе, язучы иҗаты хакында сөйләү, әсәргә карата үз мөнәсәбәтен җиткерү, автор текстына нигезләнгән монологик сөйләм әзерләү, аерым әсәрләр, әдипләр, әдәби күренешләр һ.б. хакында сөйләшү.

Язу (язма сөйләм культурасын) күнекмәләрен бәяләү өчен биремнәр: әдәби әсәр буенча куелган сорауларга язмача җавап әзерләү, әсәргә мөстәкыйль бәяләмә, сочинение элементлары белән изложение, сочинение һәм әсәргә яки билгеле бер темага мөнәсәбәтле хикәяләр һ.б. язу.

Анализ күнекмәләрен һәм теоретик белемнәрне бәяләү өчен биремнәр: әсәрнең төр һәм жанр үзенчәлекләрен табу, геройларга, образлар системасына бәя бирү, автор һәм хикәяләүченең вазифасын ачыклый алу, образларның мәгънәләрен табу, стиль, тел-сурәтләү чараларын табу һәм тексттагы функциясен билгеләү, сюжет барышын тикшерү, сюжет элементларын табу, тема-проблема, идеяне билгеләү, әдәби әсәрдәге вакыйгаларны һәм геройларны чагыштыру .

Әлеге бирем төрләреннән тыш, укучыларның белем, күнекмәләрен тикшерү максатыннан тестлар, тест тибындагы биремнәр кулланыла. Тестларның уңайлылыгы аларны тикшерү эшен тиз, төгәл оештырырга, дөрес һәм дөрес булмаган җавапларны чагыштырырга мөмкинлек бирә.

**Укучыларның укуын һәм белем-күнекмәләрен бәяләү.**

Укучыларның 1 минутка уку тизлеге түбәндәгечә бәяләнә:

| | Иҗек саны | | Сүз саны | |
|---|---|---|---|---|
| | 1 яртыеллык | 2 яртыеллык | 1 яртыеллык | 2 яртыеллык |
| V | 155-235 | 160-250 | 65-105 | 70-110 |
| VI | 160-250 | 170-270 | 70-110 | 75-115 |
| VII | 170-270 | 180-280 | 75-120 | 80-125 |
| VIII-IX | 180-280 | 190-290 | 80-125 | 85-130 |

Искәрмә.Эчтән уку тизлеге, кычкырып уку белән чагыштырганда, 5-7 нче классларда – 30-40 % ка, ә 8-9 нчы классларда 40-50 % ка югырырак була.

Уку барышында үтәлергә тиешле фонетик, орфоэпик, пунктуацион, грамматик таләпләрнең үтәлешенә нигезләнеп, бәяләр куелырга мөмкин.

| № | Таләпләр | Билге |
|---|---|---|
| 1.<br><br><br><br><br>2. | Шул сыйныфка таләп ителгән күләмдәге сүзләр (текст) тиз, ачык, дөрес әйтелеп, фикер аңлаешлы бирелсә, ягъни:<br>фонетик үзенчәлекләр (хәрефләрнең укылыш үзенчәлекләре) дөрес бирелсә;<br>татар әдәби теленең орфоэпик нормалары (сүзнең язылыш һәм әйтелеш үзенчәлекләре) сакланса;<br>җөмләләр сөйләмнең төп структур берәмлекләренә (сүзләр – иҗекләргә, җөмлә - сүз тезмәләре һәм сүзләргә, мәгънәле кисәкләргә) дөрес бүленсә;<br>туктальшлар (паузалар) дөрес ясалса, сүз басымы һәм логик басым дөрес укылса яисә куелса, интонацион яктан текстттагы җөмләләр дөрес тавыш белән укылса;<br>Укытучының текст эчтәлегеннән чыгып бирелгән сорауларына төгәл җавап бирелсә; | “5”ле билгесе куела. |
| 1.<br><br><br><br><br><br>2. | Таләп ителгән күләмдәге сүзләр (текст) тиешле тизлектә укылса, ләкин кайбер сүзләрнең әйтелешендә фонетик, орфоэпик үзенчәлекләр тиешенчә үтәлмәсә, ягъни:<br>кайбер сүзләрне укыганда, сүзләрнең укылыш үзенчәлекләре орфоэпик нормаларга туры килмәсә;<br>сөйләмнең структур бүленешендә кайбер хаталар булса;<br>җөмләне укыганда, интонацион яктан 1-2 төгәлсезлек җибәрелсә;<br>Укытучының  сорауларына төгәл җавап бирелсә; | “4”ле билгесе куела. |
| 1.<br><br>2.<br>3. | Уку тизлеге вакыт чикләренә сыймаса һәм уку барышында 3-4 фонетик, 2-3 орфоэпик хата җибәрелсә;<br><br>Текст сөйләм берәмлекләренә тиешенчә бүленмәү сәбәпле, интонация төгәл бирелмәсә;<br>Текстны аңлап та, сорауларга бирелгән җавапларда төгәлсезлекләр булса; | “3”ле билгесе куела. |
| 1.<br>2.<br>3.<br><br>4. | Тиешле тизлектә уку күнекмәләре булмаса;<br>Уку барышында үтелгән орфограммаларда төгәлсезлекләр күп кабатланса;<br>Уку барышында җибәрелгән фонетик, орфоэпик, интонацион хаталар текст эчтәлеген аңлауга комачауласа;<br>Текст эчтәлеге буенча бирелгән сорауларга өлешчә генә җавап алынганда. | “2”ле билгесе куела. |

**Телдән җавапларны бәяләү.**

Телдән җавап бирү – тәкъдим ителгән теманы сөйләү формасында була.

М а т е р и а л:

1) программа материалы буенча бирелгән яисә үзе сайлап алган тема;
2) эчтән укылган текстның (нигездә, әдәби әсәрдән яисә әдәбият дәреслегеннән алынган, күрсәтелгән яисә үзе сайлап алган) эчтәлеге.

С ө й л ә ү г ә   б и р е л ә   т о р г а н   в а к ы т:
V - VI класста 2-5 минут.
VII класста 3-6 минут.
VIII класста 4-7 минут.
IX класста 5-7 минут.
X - XI классларда 7-10 минут.

## Әдәбият дәфтәренә таләпләр

Әдәбият дәфтәрендә һәр укуелы дәвамында түбәндәге төп язмалар була:

1) планнар
2) эчтәлекне хикәяләп язу
3) цитаталар (күчереп язу)
4) аңлатмалар (сүз һәм төшенчәләргә)
5) фикер язмалары (үз фикереңне язып кую)
6) укучы үзе иҗат иткән әдәби әсәрләр (хикәяләр, шигырьләр, мәзәкләр, сценарийлар һ.б)
7) халык авыз иҗатыннан җирле материаллар
8) аннотацияләр (11кл.)
9) тезислар (8-11кл.)
10) конспектлар (8-11 кл.)
11) рефератлар (8-11 кл.).

Әдәбият дәфтәрендә бары тик программа материалын үзләштерүгә һәм аны язып бирә белергә өйрәтә торган язмалар гына булырга тиеш. Язма эшләр сочинение таләпләре белән бәяләнә.

Әдәбияттан белем дәрәҗәсен бәяләү соңгы чиктә сочинение яздыру белән йомгакланса да, өлгереш билгеләре чыгарган вакытта аның белән генә чикләнмичә, уку, сөйләү, телдән җавап бирү дә исәпкә алына.

**Укуга карата төп таләп – сәнгатьле уку.**

Уку материалы:

1. Укучы үзе язган текст яки сочинение.
2. Әдәби әсәрдән, публицистик һәм фәнни хезмәттән өзек.

Материалның күләме:

Һәр класс өчен билгеләнгән сочинение күләме икеләтә алына.

Материалны сайлап алу:

1. Укучы үзе сайлый, үзе теләгән текстны укый.
2. Укытучы күрсәтмә бирә.

<u>Укуны әдәбият фәне буенча бәяләү өчен таләпләр:</u>

1. Уку тел (грамматика) фәне буенча уңай билге куярлык булсын.
2. Сәнгатьле яисә логик сәнгатьле (текстның характерыннан чыгып) башкарылсын.
3. Уку интонациясен бөтен текстка һәм аның аерым өлешләренә карата укучы аңлатып бирә белсен.

И с к ә р м ә. Уку интонациясен аңлатканда:

1. V – VII классларда интонациянең текст эчтәлегенә карата булган ягын аңлату җитә (ягъни объектив эчтәлектән чыгып).
2. VIII класста авторның тексттагы эчтәлеккә мөнәсәбәтен чагылдыру дәрәҗәсенә бәйләп аңлату да таләп ителә.
3. IX - XI классларда укучы, болар өстенә, текст эчтәлегенә үзенең мөнәсәбәтен, тыңлаучыларга ничек тәэсир итәргә, аларда нинди хисләр уятырга теләгәнлеген дә аңлатырга тиеш.

Соңгы ике таләптән берсенең үтәлмәве тел буенча куелган билгене – бер баллга, икесенең дә кимчелекле үтәлүе билгене ике баллга киметә. Икесе дә бөтенләй үтәлмәгән булса, әдәбияттан “2”ле куела.

**Минутка укыганда куела торган таләпләр**

| № | Таләпләр | Билге |
|---|---|---|
| 1<br><br><br><br><br><br><br><br><br>2 | Шул сыйныфка таләп ителгән күләмдәге сүзләр (текст) тиз, ачык, дөрес әйтелеп, фикер аңлаешлы бирелсә, ягъни:<br>-фонетик үзенчәлекләр (хәрефләрнең укылыш үзенчәлекләре) дөрес бирелсә;<br>-татар әдәби теленең орфоэпик нормалары (сүзнең язылыш һәм әйтелеш үзенчәлекләре) сакланса;<br>-җөмләләр сөйләмнең төп структур берәмлекләренә (сүзләр-иҗекләргә; җөмлә-сүз тезмәләре һәм сүзләргә, мәгънәле кисәкләргә) дөрес бүленсә;<br>-тукталышлар (паузалар) дөрес ясалса, сүз басымы һәм логик басым дөрес укылса яисә язылса;<br>-интонацион яктан тесткtагы җөмләләр дөрес тавыш белән укылса;<br>Укучының текст эчтәлегеннән чыгып бирелгән сорауларга төгәл җавап бирелсә; | “5”ле куела |
| 1 | Таләп ителгән күләмдәге сүзләр (текст) тиешле тизлектә укылса, ләкин кайбер сүзләрнең әйтелешендә фонетик, орфоэпик үзенчәлекләр тиешенчә үтәлмәсә, ягъни:<br>-кайбер сүзләрне укыганда, сүзләрнең укылыш үзенчәлекләре орфоэпик нормаларга туры килмәсә;<br>-сөйләмнең структур бүленешендә кайбер хаталар булса;<br>-җөмләне укыганда, интонацион яктан 1-32 төгәлсезлек җибәрелсә;<br>Укытучының сорауларына төгәл җавап бирсә | “4”ле куела |

| | | |
|---|---|---|
| 1<br><br>2 | Уку тизлеге вакыт чикләренә сыймаса һәм уку барышында 3-4 фонетик,2-3 орфоэпик хата җибәрелсә;<br>Текст сөйләм берәмлекләренә тиешенчә бүленмәү сәбәпле, интонация төгәл бирелмәсә;<br>Текстны аңлап та, сорауларга бирелгән җавапларда төгәлсезлек булса; | “3”ле куела |
| 1<br>2<br><br><br>3 | Тиешле тизлектә уку күнекмәләре булмаса;<br>Уку барышында үтелгән орфограммаларда төгәлсезлекләр күп кабатланса;<br>Уку барышында җибәрелгән фонетик, орфоэпик, интонацион хаталар текст эчтәлеген аңлауга комачауласа;<br>Текст эчтәлеге буенча бирелгән сорауларга өлешчә генә җавап алынганда; | “2”ле куела |

**Сочинение бәяләү нормалары**

| № | Эшнең эчтәлеге һәм теле | Грамоталылыгы | Билге |
|---|---|---|---|
| 1 | Эчтәлек темага туры килә; язмада фактик ялгышлар юк;план (яки плансыз) эзлекле язылган;теле бай, образлы, стиль бердәмлеге сакланган | 1 орфографик яки пунктуацион (яки грамматик) хата бар | “5”ле куела |
| 2 | Язманың эчтәлеге темага туры килә, ул дөрес ачылган; 1 фактик хата җибәрелгән, хикәяләү эзлеклелелегендә артык әһәмияте булмаган бозу сизелә;тулаем алганда, теле бай, образлы; стиль бердәмлеге сакланган | 2 орфографик,1 пунктуацион (яки1 грамматик) хата бар | “4”ле куела |
| 3 | Эчтәлекне бирүдә мөһим читләшүләр бар: ул нигездә дөрес, ләкин фактик төгәлсезлекләр очрый, хикәяләү эзлекле түгел; телнең ярлылыгы сизелеп тора; синонимик сүзләрне аз куллана, бертөрлерәк синтаксик төзелмәләр файдалана, образлы түгел, сүз куллануда ялгышлар җибәрә; стиль бердәмлеге сакланып җитмәгән. | 3 орфографик,2 пунктуацион 1 грамматик хата бар | “3”ле куела |
| 4 | Тема ачылмаган; фактик төгәлсезлекләр күп, планга туры килми, эзлеклелек бозылган; теле ярлы; сүз куллану ялгышлары еш очрый; стиль бердәмлеге юк. | Орфографик хаталарның саны 3тән, пунктуацион хаталарның саны 2дән, грамматик хаталарның саны 3 тән артык | “2”ле куела |
| 5 | Төгәлсезлекләр билгесе “2”ле кую нормасыннан артып китә. | Төгәлсезлекләр “2”ле кую нормасыннан артып китә. | “1”ле билгесе куела |

**Агымдагы контроль һәм йомгаклау контроле өчен түбәндәге материаллар** кулланыла: тест биремнәре, мөстәкыйль эшләр,телдән җаваплар,тикшерү диктантлары , изложение,сочинение ,әңгәмә. 5 нче сыйныфта әлеге эш программасын тормышка ашырганда
аңлату-күрсәту;
репродуктив,
проблемалы укыту методы,
өлешчә эзләнү (эвристик) методлары;
үстерелешле укыту технологиясе;
информацион-коммуникатив **технологияләр һәм методлар** кулланыла..

**Материаль –техник тәэмин ителеш:**

-стендлар
-компьютер
-медиаресурслар комплекты
-плакатлар
-әдәби китаплар,методик әсбаплар торган китапханә
-мөстәкыйль эшләү өчен биремнәр
-басма материаллар, матбугат материаллары
-тарату карточкалары
-тарату тестлары
-“Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”
-Телара сүзлекләр
-Папкада тупланган материаллар

**Укыту- методика комплексы:**

Дәреслек:“Әдәбият”: Татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы 5 нче сыйныфы өчен дәреслек. Ф.Ә.Ганиева, Л.Г.Сабирова - Казан: Татарстан китап нәшрияты , 2014

**Интернет ресурслар:**

http://gabdullatukay.ru/
http://mojahit.narod.ru/
http://gibrahimov.ucoz.ru/
http://alish.ru/

# <u>Әдәбияттан календарь-тематик план</u>

**Сыйныф:** <u>5</u>

**Укытучы:** <u>Нәҗметдинова Л.Ә.</u>

**Сәгатьләрсаны:**

Барысы– <u>70</u> сәгать; атнага – <u>2</u> сәгать.

Шулар арасында: әсәрләр өйрәнү – 57 сәгать, бәйләнешле сөйләм үстерү – <u>8</u> сәгать ( сочинение язу), тест -<u>1</u> сәг.(арадаш аттестация практик дәрес хисабына) класстан тыш уку - <u>4</u> сәгать

***Программа:*** Татар урта мәктәпләре өчен әдәбият программалары (5-11 нче сыйныфлар). – Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2010.
Д.Ф.Заһидуллина, И.М.Йосыпова җитәкчелегендә эшләнгән “Татар телендә гомуми төп белем бирү мәктәпләре өчен (5-9) татар әдәбиятыннан үрнәк программа, Казан-2013

***Дәреслек-хрестоматия***: “Әдәбият”: Татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы 5 нче сыйныфы өчен дәреслек. Ф.Ә.Ганиева, Л.Г.Сабирова - Казан: Татарстан китап нәшрияты , 2014

Кулланылган кыскартылма сүзләр:

КТ – контроль төре,
ИР – Интернет ресурсы,
МТК – милли-төбәк компоненты,
ӘТ - әдәбият теориясе,
* - катлауландырылган бирем, КТЧ – класстан тыш чара, МК – методик кулланма (Җәләлиева М.Ш., Сибгатуллина Д.Ш. 5 нче сыйныфта әдәбият: укытучылар өчен методик кулланма. - Казан: Мәгариф, 1999)

## Календарь –тематик план

| № | Дәрес темасы | Дәрес тибы | Үзләштерелгән материал буенча көтелгән нәтиҗәләр | Уку эшчәнлеге төрләре | Контроль төрләре | Дата | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | План | Факт. |
| | **Халык авыз иҗаты—1 сәг.** | | | | | | |
| 1 | **Халык авыз иҗаты.** Аның әсәрләрендә гомумкешелек хыяллары, идеалларының чагылуы. | Кереш дәрес | Халыкның милли, рухи мәдәният хәзинәсе буларак халык иҗаты. Аның сәнгать төрләре формалашуга йогынтысы. Халык иҗатының бер төре буларак халык авыз иҗаты. Аның әсәрләрендә гомумкешелек хыяллары, идеалларының чагылуы. Халык авыз иҗатының матур әдәбият белән бәйләнешләре: уртаклыгы һәм үзенчәлекле аермалары. Халык авыз иҗатының төп жанрлары, жанр сыйфатлары | -фольклор әсәрләренең жанрын һәм аларга хас үзенчәлекләрне таный алу; -фольклор әсәрләрен аңлап, иҗади, сәнгатьлеукый белү; укыганны телдән сурәтләп бирә алу; рольләргә кереп кабатлап бирү; -төрле мәгълүмат чыганаклары (сүзлекләр, белешмәләр, энциклопедияләр, электрон чаралар) белән максатчан эшли белү | КТ: Сорауларга җавап алу | 03.09 | |
| | **Әкиятләр-8 сәг.** | | | | | | |
| 2 | **Әкиятләр**. Жанр төрләре, үзенчәлекле сыйфатлары. Әкиятләрнең эстетик кыйммәте | Яна материалны өйрәнү дәресе | Әкиятләр, жанр төрләре, үзенчәлекле сыйфатлары.Әкиятләрнең эстетик кыйммәте | -әкиятләрне аңлап уку, эчтәлеген кабатлап сөйли, кирәк чакта тексттан өзекләр китерә алуга ирешү; | КТ: Әкияттә катнашучы ларның исемлеген язу. | 06.09. | |
| 3 | "Ак бүре" әкияте. Әкият героеның сыйфатлары | Әдәби текст белән танышу һәм анализлау | Сәнгатьле уку күнекмәләренә ия булу | - әкиятләрнең төрләрен аера алу; | КТ: Әкияттә катнашучы ларның исем леген язу | 10.09 | |
| 4 | "Ак бүре" әкияте. Эчтәлекне өйрәнү . | Әдәби текст белән танышу һәм анализлау | Әкиятләр, жанр төрләре, үзенчәлекле сыйфатлары.Әкиятләрнең эстетик кыйммәте | - әкиятләргә халык акылы, тапкырлыгы, зирәклеге, батырлыгы салынуын аңлау, шул турыда уйларга өйрәнү; | Сорауларга җавап бирү | 13.09 | |
| 5 | "Ак бүре" әкияте. Йомгаклау | Әсәрне сәнгатьле уку һәм нәтиҗәләр чыгару | Әкиятләр, жанр төрләре, үзенчәлекле сыйфатлары.Әкиятләрнең эстетик кыйммәте | -тормыштан алган фикер-карашларга, хис-кичерешләргә нигезләнеп, өйдә иҗади эш башкару. | Тест биремнәре эшләү | 17.09 | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | дәресе. | | | | | |
| 6 | “Үги кыз”әкияте. Герой холкындагы гаделлек, тугрылык | Яна материалны өйрәнү дәресе | Герой холкындагы гаделлек, тугрылык | -әкиятләрне аңлап уку, эчтәлеген кабатлап сөйли, кирәк чакта тексттан өзекләр китерә алуга ирешү; | КТ: Әкият эчтә леген ача торган мәкальләр туплап язу. КТ:29 нче бит: 1-7 нче сорау ларга җавап бирү | 20.09 | |
| 7 | “Үги кыз”әкиятен өйрәнүне йомгаклау. | Әсәрне сәнгатьле уку һәм нәтиҗәләр чыгару дәресе. | Әкиятләр, жанр төрләре, үзенчәлекле сыйфатлары.Әкиятләрнең эстетик кыйммәте | - әкиятләрнең төрләрен аера алу; | Сорауларга җавап бирү | 24.09 | |
| 8 | “Аю белән төлке” әкияте. Әкиятләрдә кешегә хас сыйфатларның һәм фикер йөртүнең хайваннарга, табигать җисемнәренә үзенчәлекле төстә күчерелүе | Яна материалны өйрәнү дәресе | Әкиятләр, жанр төрләре, үзенчәлекле сыйфатлары.Әкиятләрнең эстетик кыйммәте | - әкиятләргә халык акылы, тапкырлыгы, зирәклеге, батырлыгы салынуын аңлау, шул турыда уйларга өйрәнү | Сорауларга җавап бирү | 27.09 | |
| 9 | “Аю белән төлке” әкияте. Аны уку, текстка якын итеп, балалардан сөйләтү | Әдәби текст белән танышу дәресе | Әкиятләр, жанр төрләре, үзенчәлекле сыйфатлары.Әкиятләрнең эстетик кыйммәте | Әкиятләрдә кешегә хас сыйфатлар ның һәм фикер йөртүнең хайваннарга, табигать җисемнәренә үзенчәлекле төстә күчерелүен белү | Сорауларга җавап бирү | 01.10 | |
| 10 | **БСҮ**.Мин әкият яратам. | Бәйләнешле сөйләм үстерү дәресе | Бәйләнешле сөйләм үстерү | -тормыштан алган фикер-карашларга, хис-кичерешләргә нигезләнеп, өйдә иҗади эш башкару. | Сочинение язу | (4)08. 10 | |
| 11 | **БСҮ**.Мин әкият яратам. | Бәйләнешле сөйләм үстерү дәресе | Бәйләнешле сөйләм үстерү | -тормыштан алган фикер-карашларга, хис-кичерешләргә нигезләнеп, өйдә иҗади эш башкару. | Сочинение язу | 11.10 | |
